Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXXII-10**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 24 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы депутатлары А. М. Фатиховның, Ш.А. Мәхмүтовның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге башлыгы Фатихов А. М., Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге башлыгы Мәхмүтов Ш. А.ның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылу сәбәпле, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 маддәсендәге 10.2, 11 өлешләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 29 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 36 маддәсенең 1 өлешендәге 9 пункты, 36 маддәсенең 3 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы депутатлары Фатихов Азат Миңневәзыйх улының, Мәхмүтов Шамил Габделкәрим улының, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк һәм Шумково авыл җирлекләре башлыклары булараk үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату сәбәпле, тиңдәшле рәвештә вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советы рәисе урынбасары И.Г. Ибраһимов